| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 15 » июнь 2021 с. Тюлячи № 208

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 16 октябрендәге 621 номерлы «Авиация эшләрен башкаруга, парашют сикерүләргә, һава судноларының демонстрацион очышларына, пилотсыз һава суднолары (максималь очып китү массасы 0,25 килограммнан кимрәк булган пилотсыз һава суднолары очышларыннан тыш) очышларына рөхсәтләр бирү, Теләче муниципаль районы территориясе өстендә аэростатлар күтәрелү, белешмәләр аэронавигация мәгълүматы документларында басылып чыкмаган Теләче муниципаль районы чикләрендә урнашкан мәйданчыкларга очып төшү (очып китү) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 509-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 16 октябрендәге 621 номерлы «Авиация эшләрен башкаруга, парашют сикерүләргә, һава судноларының демонстрацион очышларына, пилотсыз һава суднолары (максималь очып китү массасы 0,25 килограммнан кимрәк булган пилотсыз һава суднолары очышларыннан тыш) очышларына рөхсәтләр бирү, Теләче муниципаль районы территориясе өстендә аэростатлар күтәрелү, белешмәләр аэронавигация мәгълүматы документларында басылып чыкмаган Теләче муниципаль районы чикләрендә урнашкан мәйданчыкларга очып төшү (очып китү) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» карарына ( 14.03.2018 № 141, от 27.04.2020 № 196, 31.12.2020 № 619, 12.04.2021 № 162 карарлар редакциясендә) (алга таба - карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Авиация эшләрен башкаруга, парашют сикерүләргә, һава судноларының демонстрацион очышларына, пилотсыз һава судноларын

(максималь очып киту массасы 0,25 килограммнан кимрәк булган пилотсыз һава суднолары очышларыннан тыш) очышларына рөхсәтләр бирү, Теләче муниципаль районы территориясе өстендә аэростатлар күтәрелү, белешмәләр аэронавигация мәгълүматы документларында басылып чыкмаган Теләче муниципаль районы чикләрендә урнашкан мәйданчыкларга очып төшү (очып китү) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына

А) III бүлекнең исемен түбәндәге тәртиптә бәян итәргә: «Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре. Бүлек дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүнең күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтүнең гомуми билгеләре белән берләшкән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә бирү тәртибе вариантларын да үз эченә алган булырга тиеш, шул исәптән дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүләр нәтиҗәсенә карата да.».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Ф.С. Валеевка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин